ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЕЛАБУЖСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АЛАБУГА МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫБАШКАРМА
КОМИТЕТЫ

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** 06.06.2024 764 **КАРАР**

Алабуга муниципаль районында «Сабан туе сылуы - 2024» муниципаль ачык конкурсын үткәрү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә һәм татар халкының «Сабан туе» милли бәйрәмен билгеләү уңаеннан, Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Алабуга муниципаль районында «Сабан туе сылуы - 2024» муниципаль ачык конкурсын уздыру турында Нигезләмәне (1 нче кушымта) расларга.
2. Алабуга муниципаль районында «Сабан туе сылуы - 2024» муниципаль ачык конкурсын уздыруга чыгымнар сметасын расларга (2 нче кушымта).
3. Алабуга муниципаль районының Финанс-бюджет палатасына (Садыйкова Э.И.) Алабуга муниципаль районының җирле бюджетыннан смета нигезендә акча бүлеп бирүне тәкъдим итәргә.
4. Әлеге карар рәсми рәвештә бастырып чыгарылырга тиеш.
5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары Н.Д. Курамшинга йөкләргә.

Җитәкче

ДОКУМЕНТ ПОДПИСАН
ЭЛЕКТРОННОЙ ПОДПИСЬЮ
СВЕДЕНИЯ О СЕРТИФИКАТЕ ЭП
Сертификат: 30C33C67746B0C8EA9DE00B6707B1433
Владелец: Ахмадеева Эльмира Равильевна
Действителен с 19.10.2023 до 11.01.2025

Э.Р. Әхмәдиева

Алабуга муниципаль районы
Башкарма комитеты карарына
1нче кушымта

06.06.2024
764

**РАСЛЫЙМ**
**Алабуга муниципаль районы**
**Башкарма комитеты җитәкчесенең**
**социаль үсеш буенча**
**___________________Н.Д. Курамшин**

**КИЛЕШЕНДЕ**

**«Алабуга муниципаль районы Башкарма комитетының мәдәният идарәсе» МКУ башлыгы _______________ Д.А. Камалова**

**Алабуга муниципаль районы «Йолдызлык» мәдәни-күңел ачу үзәге МБУ директоры______________Е.О. Морозова**

# «Сабан туе сылуы - 2024»
# муниципаль ачык конкурсын үткәрү турында
# НИГЕЗЛӘМӘ

## Конкурсны гамәлгә куючылар

Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты, «Алабуга муниципаль районы Башкарма комитетының мәдәният идарәсе» МКУ, Алабуга муниципаль районы «Йолдызлык» мәдәни-күңел ачу үзәге МБУ, Алабуга шәһәре оешмалары, учреждениеләре һәм предприятиеләре белән берлектә.

## Конкурсның максатлары һәм бурычлары

- татар халкының традицион һәм заманча мәдәниятен үстерү һәм пропагандалау;
- яшьләр арасында талантлы кешеләрне ачыклау, милли-мәдәни традицияләргә җәлеп итү;
- милли-традицион мәдәниятне үзешчән сәнгатьнең оешкан рәвешләре аша популярлаштыру;
- яшьләргә әхлакый һәм патриотик тәрбия бирүдә мәдәниятнең әһәмиятен күтәрү;
- халык культурасының күптөрле традицияләрен һәм күренешләрен өйрәнү нигезендә халыкның эстетик зәвыгын формалаштыру.

## Конкурсны үткәрү сроклары һәм тәртибе

Конкурс өч этапта үткәрелә:

**- конкурсның сайлап алу туры 2024 елның 2 маенда 16.00 сәг. үткәрелә.** Үткәрү урыны: ТР АМР «Йолдызлык» мәдәни-күңел ачу үзәге МБУ (Мир проспекты, 77 нче йорт).

- **2024 елның 6 маеннан 4 июненә кадәр конкурс финалына әзерлек**. Үткәрү урыны: ТР АМР «Йолдызлык» мәдәни-күңел ачу үзәге МБУ Алабуга шәһәре, (Мир проспекты, 77 нче йорт). «АМР шәһәр мәдәният сарае» (Алабуга шәһәре, Нефтяниклар проспекты, 24 нче йорт).

**-- 2024 елның 6 маеннан 4 июнендә бәйгенең финалы, шоу-программа.** Үткәрү урыны: ТР АМР «Йолдызлык» мәдәни-күңел ачу үзәге МБУ (Мир проспекты, 77 нче йорт).

Муниципаль конкурс финалистлары 2024 елның 9 июнендә «Сабан туе-2024» милли бәйрәмен үткәрүдә катнаша (шәһәр Ипподромы территориясе). Җиңүче «Сабан туе – 2024 елның абсолют Батыры» бүләкләү тантанасында катнаша, аңа җиңүче тасмасын тапшыра.

Конкурста катнашуга гаризалар 2024 елның 1 маена кадәр түбәндәге формада кабул ителә: cdcsoz@mail.ru электрон почта аша (әлеге Нигезләмәнең 1 нче кушымтасы).

Белешмә өчен телефон: **9-96-55**

## Конкурсның эчтәлеге һәм шартлары

Конкурста татар телен белүче, буе 160 см. озынрак булган. 14 яшьтән 30 яшькә кадәрге кызлар катнаша.

Конкурс программасы өч биремнән тора:

1. **«Визит карточкасы»** - 2-3 минут эчендә үз-үзеңне, гаиләңне таныштыру,

теләсә нинди жанрларны (сәнгать сүзе, вокал, оригиналь жанр, хореография) кулланып. Бередә ярдәм төркеме катнаша ала, катнашучылар саны чикләнмәгән. Программаның төп катнашучысы конкурсант.

2. **«Милли костюмны яклау»**- музыкаль конкурс. Катнашучыларга татар костюмын (халык, сәхнә, стилизацияләнгән, заманча милли колорит белән) күрсәтергә һәм 1 концерт номерын (җыр, бию, шигырь, музыка коралларында уйнау) башкарырга кирәк.
3. **«Татар халкының традицион ризыгы» -** бәйге финалы көнендә катнашучылар чиратлашып жюри өчен ризыклар тәкъдим итә (финал көнендә).

Катнашучыларга үзләре белән икенче аяк киеме, сәхнә костюмы, флеш-саклагычтагы фонограмма булырга тиеш.

**Бәяләүнең төп критерийлары**

- башкару осталыгы һәм сәхнә культурасы дәрәҗәсе;
- татар телен дөрес белү;
- татар халкының мәдәниятен, милли йолаларны һәм гореф-гадәтләрне белү;
- артистлык булу, эстетик зәвык, оригинальлек;
- стильнең, башкару манераларының, сәхнә костюмының туры килүе.

Конкурста катнашучылар 10 баллы система буенча бәяләү критерийлары нигезендә конкурс жюрие тарафыннан бәяләнә. Иң күп балл җыйган катнашучылар конкурс җиңүчеләре дип таныла.

**Конкурс жюрие**

Конкурска бирелгән иң яхшы эшләрне бәяләү һәм ачыклау, җиңүчеләрне билгеләү өчен жюри төзелә.

Конкурс өстәлне бәяләү жюри әгъзалары тарафыннан критерийлар нигезендә эксперт бәяләве методы белән башкарыла.

Жюри утырышлары жюри әгъзаларының гомуми саныннан 2/3 катнашу шарты белән хокуклы дип санала.

Жюри карары гади күпчелек тавыш белән кабул ителә.

Тавышлар тигез булганда комиссия рәисенең тавышы хәлиткеч тавыш булып тора.

Жюри карары беркетмәләр белән рәсмиләштерелә.

**Бүләкләү тәртибе**

Муниципаль конкурс нәтиҗәләре буенча җиңүчегә таҗ, тасма, җиңүче дипломы һәм кыйммәтле бүләк белән **«Сабан туе сылуы-2024»** исеме бирелә.

Шулай ук дипломнар һәм кыйммәтле бүләкләр тапшырып, 2 һәм 3 урыннар бирелә. Калган катнашучылар катнашучының дипломнары һәм истәлекле бүләкләр белән бүләкләнәләр.

Жюри катнашучыларны бүләкләү өчен махсус призлар билгеләү хокукын үзендә калдыра: тамашачылар симпатиясе призы, милли традицияләргә аерым тугрылык өчен приз һ. б.

**«Сабан туе сылуы - 2024»**
**муниципаль ачык конкурсын уздыру турында**
**Нигезләмәгә 1 нче кушымта**

## Гариза-анкета

1. Фамилиясе, исеме, атасының исеме*
2. Туган елы_______________________________________________________.
3. йорт адресы, телефон___________________________________________
4. Уку урыны, эш урыны________
5. Паспорт күрсәткечләре
(№, серия, кайда һәм кем тарафыннан бирелгән)_________
6. Салым түләүченең идентификация номеры
7. Иминият пенсия таныклыгы__________
8. Сезнең мавыгуларыгыз, мәнфәгатьләрегез________
9. Сезнең сәләтегез (кирәклесен сызарга):
а) җырлыйм б) музыка коралында уйныйм
в) биим г) яттан сөйлим
д) һәм башкалар
10. Татар телен белү (кирәклесен ассызыкларга):
а) яхшы Б) бик яхшы
в) уртача г) начар
11. Буегыз